Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №III-10**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 16 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 5 августындагы "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында" LIV-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р, 2020 елның 14 августындагы 1536-р номерлы Күрсәтмәләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 5 августындагы "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында" LIV-4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1 пунктта:

1.1.1 "а" пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар – кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручыларның коммерциягә карамаган оешмалар реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы оешмалар мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде эш көне эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 октябренә кадәр түбәндәге шартларда аренда түләүләрен түләүне кичектерүне күздә тотучы өстәмә килешүләр төзү:

аренда түләве буенча бурыч арендаторлар тарафыннан тәкъдим ителгән срокта 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап түләнә, айга бер тапкырдан да еш түгел, бу тигез

түләүләрнең күләме аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмый;

кичектереп торуга бәйле рәвештә штрафлар, чит акчалардан файдаланган өчен процентлар яисә арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле рәвештә җаваплылыкның башка чаралары кулланылмый (шул исәптән, мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда);

кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

аренда шартнамәсе вакытыннан алда өзелгәндә аренда түләве буенча бурыч бер түләүдә түләнә;”;

1.1.2 “б” пунктчасында “кече һәм урта эшкуарлык субъектлары” сүзләреннән соң “социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар” сүзләрен өстәргә;

1.2 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар – кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручыларның коммерциягә карамаган оешмалар реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы оешмаларга аренда түләүләрен түләүне кичектерү бирелә дип билгеләргә, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага аларның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча узган чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк.”

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Г. Әхмәтҗанова